КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 26 декабрь г.Казань № 1195

2021 елга Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәтен хосусыйлаштыруның фаразлау планы (программасы) турында

«Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәтен хосусыйлаштыру турында» 2004 елның 26 июлендәге 43-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Карарга теркәлгән 2021 елга Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәтен хосусыйлаштыруның фаразлау планын (программасын) расларга.
2. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2020 ел, 26 декабрь, 1195 нче
карары белән расланды

# 2021 елга Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәтен хосусыйлаштыруның фаразлау планы (программасы)

## I кисәк

## 2021 елда Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәтен хосусыйлаштыру өлкәсендә дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыруның төп юнәлешләре

2021 елга Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәтен хосусыйлаштыруның фаразлау планы (программасы) «Дәүләт һәм муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру турында» 2001 елның 21 декабрендәге 178-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәтен хосусыйлаштыру турында» 2004 елның 26 июлендәге 43-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә Татарстан Республикасын социаль-икътисадый үстерүнең төп бурычларын исәпкә алып эшләнде.

2021 елда Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәтен хосусыйлаштыруның фаразлау планын (программасын) гамәлгә ашыруның төп максаты Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәте белән идарә итүнең һәм аның керемнәренең максималь нәтиҗәлелеген тәэмин итүдән гыйбарәт.

Татарстан Республикасының икътисадый үсеш өстенлекләрен исәпкә алып, 2021 елда Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәтен хосусыйлаштыру өлкәсендә дәүләт сәясәтенең төп бурычлары түбәндәгеләр:

җитештерү-инновацион структураларга инвестицияләр җәлеп итү;

дәүләт мөлкәте составын һәм структурасын оптимальләштерү;

Татарстан Республикасы бюджеты керемнәрен формалаштыру.

Югарыда күрсәтелгән бурычларны хәл итү кысаларында 2021 елда Татарстан Республикасы милкендәге акционер җәмгыятьләрнең акцияләрен хосусыйлаштыру планлаштырыла.

Финанс елы тәмамланганнан соң хосусыйлаштырылмаган чын Фаразлау планына (программасына) кертелгән дәүләт мөлкәте чираттагы финанс елында хосусыйлаштырылырга тиеш.

II кисәк

Хосусыйлаштыру 2021 елда планлаштырыла торган Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәте

Акцияләрен 2021 елда хосусыйлаштыру планлаштырыла торган акционерлык җәмгыятьләр исемлеге

| Акционерлык җәмгыяте исеме | «Алтын акция» булу | Устав капиталында Татарстан Республикасы өлеше, процентлар | Акцияләрнең хосусыйлаштырыла торган пакеты (өлеше), процентлар |
|---|---|---|---|
| Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы | | | |
| «Түбән Кама ресурслары» акционерлык җәмгыяте | юк | 11,99 | 11,99 |
| Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы | | | |
| «Алабуга икмәк кабул итү предприятиесе» ачык акционерлык җәмгыяте | бар | 7,69 | 7,69 |
| «Бөгелмә элеваторы» ябык акционерлык җәмгыяте | юк | 25 процент + 1 акция | 25 процент + 1 акция |
| Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы | | | |
| «КАИ-Лазер» сәнәгать лазер технологияләренең төбәк инжиниринг үзәге» акционерлык җәмгыяте | юк | 71,73 | 71,73 |
| «Медицина Фәне үзәге» медицина симуляторларының төбәк инжиниринг үзәге» акционерлык җәмгыяте | юк | 50,93 | 50,93 |
| «Үзебезнең робот техникасын прототиплаштыру һәм гамәлгә кертү үзәге» акционерлык җәмгыяте | юк | 94,74 | 94,74 |

________________